**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№8375**
**22.12.2021**

Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3683 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 31 маендагы 3683 номерлы карары (Башкарма комитетның 2021 елның 12 июлендәге 4696 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.2. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую өчен гариза бирүчедән гаризалар кабул итү гамәлгә ашырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк (КФҮ) тарафыннан;

2) Регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасы аша.».

2) 2.6.1 пунктта түбәндәге пунктчаларны төшереп калдырырга:

10, 12, 22, 23;

3) 2.6.1 пунктта 20 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20) яшәү (тору) урыны турында мәгълүматлар – Россия ЭЭМ;»;

4) 2.8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

1) социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу хокукын расламый торган документлар һәм мәгълүматлар керү;

2) Регламентның 2.5.1 пункты нигезендә Гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар булмау яки алар тулысынча тутырылмау;

3) гаризада һәм тапшырылган документларда күрсәтелгәннәргә туры килмәгән мәгълүматлар ачыклану;

4) торак шартлары начарлануга китергән гамәлләр кылган көннән башлап срок (биш ел) узмаган;

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булу;

6) махсуслаштырылган оешма белән төзелгән шартнамәләр буенча гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча федераль һәм республика программалары буенча элек сатып алынган торак урын бәясен тулысынча түләмәү, шул исәптән аны түләү максатларында махсуслаштырылган оешма белән төзелгән шартнамә буенча максатчан акчалата заемны тулысынча кайтармау.»;

5) 1 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 22 декабрендәге
8375 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге______
(район, шәһәр исеме)
Башкарма комитеты Җитәкчесенә____________

гр. ________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) тулысынча)
____________________________________________
(адресы буенча шәһәрдә, поселокта, авылда яшәүче)
____________________________________________
(почта индексы, тулы адресы, элемтә телефоны)
____________________________________________
____________________________________________
____________________________________________
__________________ ______________________________
(число, ай, ел)

ГАРИЗА

________________________________________________________________________________
(торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булуның сәбәпләрен күрсәтергә)
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(бер гаилә әгъзасына торак белән тәэмин ителү
________________________________________________________________________________
социаль ипотека буенча исәпкә алу нормасыннан түбәнрәк,
________________________________________________________________________________
санитар һәм техник таләпләргә җавап бирми
________________________________________________________________________________
торган торак урында яшәү, коммуналь фатирда яшәү, биләгән торакны сүтү зарурлыгы)
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(торак хокукында биләгән объектның тибын күрсәтергә: изоляцияләнгән (коммуналь),
________________________________________________________________________________
бүлмәләр саны)
________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________ сәбәпле
____ кеше составында минем гаиләне яшь гаилә буларак социаль ипотека системасында торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алуны сорыйм.

Билгеләнгән формадагы, социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен минем гаиләне исәпкә алу өчен кирәкле мәгълүматлар тупланган анкета гаризага теркәлгән.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары җирле үзидарә органнары тарафыннан гаризада һәм анкетада күрсәтелгән мәгълүматларны тикшерүгә, шулай ук алар һәм махсуслашкан оешма тарафыннан исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документларга запрос ясауга ризалык бирәбез.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, безне исәпкә алган очракта, гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә, бер ай эчендә алар турында язма рәвештә исәп урыны буенча җирле үзидарә органнарына хәбәр итәргә тиеш булуыбыз турында кисәтелдек.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, гаризада күрсәтелгән мәгълүматларга туры килми торган мәгълүматлар ачыклаган очракта, законда билгеләнгән тәртиптә исәптән төшерелү белән килешәбез.

Моның белән тиешле салым органнарында һәм күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән килешүләр төзүне дәүләт теркәвенә алу органнарында минем керемнәрем һәм милек хокукында мин ия булган милек турында мәгълүматларны тикшерергә ризалык бирәм.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары персональ мәгълүматларны эшкәртүгә һәм аларны өченче затларга бирүгә ризалык бирәбез.

Гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре турында түбәндәге ысул белән хәбәр итүне сорыйбыз:

☐ Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында электрон рәвештә;

☐ КФҮдә.

Гариза бирүче: ____________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) тулысынча, имза)

Гаиләнең хокукка
сәләтле әгъзалары:

1.____________________________________________________________
2.____________________________________________________________
3.____________________________________________________________
4.____________________________________________________________
5.____________________________________________________________
6.____________________________________________________________

(гаиләнең хокукка сәләтле барлык әгъзаларының имзалары)

«___________» ____________ 20__ ел

(дата сүз белән)

Оешма җитәкчесенә ________________________
(район, шәһәр исеме)
______________________________ ____________
гр. _______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) тулысынча)
___________________________________________
(адресы буенча шәһәрдә, поселокта, авылда яшәүче)
___________________________________________
(почта индексы, тулы адресы, элемтә телефоны)
___________________________________________
___________________________________________
________________ __________________________
(число, ай, ел)

ГАРИЗА

_____________________________________________________________________________
(торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булуның сәбәпләрен күрсәтергә)
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
(бер гаилә әгъзасына торак белән тәэмин ителү
_____________________________________________________________________________
социаль ипотека буенча исәпкә алу нормасыннан түбәнрәк,
_____________________________________________________________________________
санитар һәм техник таләпләргә җавап бирми
_____________________________________________________________________________
торган торак урында яшәү, коммуналь фатирда яшәү, биләгән торакны сүтү зарурлыгы)
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
(торак хокукында биләгән объектның тибын күрсәтергә: изоляцияләнгән (коммуналь),
_____________________________________________________________________________
бүлмәләр саны)
_____________________________________________________________________________
______________________________________________________________________ сәбәпле
____ кеше составында минем гаиләне яшь гаилә буларак социаль ипотека системасында торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алуны сорыйм.

Билгеләнгән формадагы, социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен минем гаиләне исәпкә алу өчен кирәкле мәгълүматлар тупланган анкета гаризага теркәлгән.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары оешма тарафыннан гаризада һәм анкетада күрсәтелгән мәгълүматларны тикшерүгә, шулай ук ул һәм махсуслашкан тарафыннан исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документларга запрос ясауга ризалык бирәбез.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, безне исәпкә алган очракта, гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә, бер ай эчендә алар турында язма рәвештә исәп урыны буенча оешмага хәбәр итәргә тиеш булуыбыз турында кисәтелдек.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, гаризада күрсәтелгән мәгълүматларга туры килми торган мәгълүматлар ачыклаган очракта, законда билгеләнгән тәртиптә исәптән төшерелү белән килешәбез.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары персональ мәгълүматларны эшкәртүгә һәм аларны өченче затларга бирүгә ризалык бирәбез.

Гариза бирүче:
_____________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) тулысынча, имза)

Гаиләнең хокукка
сәләтле әгъзалары:

1.______________________________________________
2.______________________________________________
3.______________________________________________
4.______________________________________________
5.______________________________________________
6.______________________________________________

(гаиләнең хокукка сәләтле барлык әгъзаларының имзалары)

«___________» ____________ 20__ ел
(дата сүз белән)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева